**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 февралендәге 352 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 22 маендагы 1455 номерлы «Казан шәһәрендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 129 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы «Татарстан Республикасы спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларының һәм Татарстан Республикасы спорт әзерлеге буенча дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарын (аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 06 маендагы 380 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы, 2020 елның 01 сентябрендәге 768 номерлы, 2020 елның 03 ноябрендәге 989 номерлы, 2021 елның 21 июлендәге 633 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 26 маендагы 489 номерлы, 2022 елның 20 июнендәге 587 номерлы, 2022 елның 14 сентябрендәге 1002 номерлы, 2022 елның 30 ноябрендәге 1268 номерлы, 2023 елның 17 июлендәге 846 номерлы, 2024 елның 3 апрелендәге 215 номерлы, 2024 елның 26 апрелендәге 283 номерлы, 2024 елның 21 июнендәге 447 номерлы, 2024 елның 12 сентябрендәге 766 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 22 маендагы 1455 номерлы «Казан шәһәрендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 8 июнендәге 1421 номерлы, 2022 елның 27 июлендәге 2392 номерлы, 2023 елның 5 июнендәге 1566 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 543 номерлы, 2024 елның 11 сентябрендәге 3848 номерлы

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1. II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

**«II. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү**

2.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Физик культура буенча инструктор | 22 663 |
| Икенче | Педагог-оештыручы | 22 758 |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче | Педагог-психолог | 22 858 |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | 23 008 |
| Икенче | Балаларга гомуми белем бирү программасын һәм өстәмә белем бирү буенча мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган аерым структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 23 058 |

2.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |

| | |
|---|---|
| Аккомпаниатор | 22 820 |
| «Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Тавыш операторы | 23 320 |
| Рәссам-бизәүче | |

2.3. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда медицина хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче | Шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат)) | 23 121 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина хезмәткәре (ир-ат)) | |
| Бишенче | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медицина хезмәткәре (ир-ат))* | 24 821 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 26 521 |

*Вазифа оешма буйсынуында өч һәм аннан артык шәфкать туташы (медицина хезмәткәре (ир-ат) булган очракта билгеләнә.

2.4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Бер айга төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Спорт залы буенча дежур | 21 200 |
| | I төркем инвалид спортчыны озатып йөрүче | |
| Икенче | Спортчы | 21 200 |
| | Әйдәүче спортчы | |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Адаптив физик культура инструкторы | 22 063 |
| | Спорт инструкторы | |
| | Спортчы-инструктор | |
| | Атны өйрәтүче тренер | |
| Беренче | Спорт техникасыннан файдалану һәм аны ремонтлау буенча техник | 22 063 |
| Икенче | Тренировкалар процессы администраторы | 22 070 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| | Адаптив физик культура инструктор-методисты | |
| | Адаптив физик культура буенча тренер-укытучы | |
| | Хореограф | |
| Өченче | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист | 22 076 |
| | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы | |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Аналитик (спорт төрләренең төре яки төркеме буенча) | 22 133 |

2.5. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| «Икенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Ветеринария фельдшеры | 22 776 |
| Икенче | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификация) | |
| «Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Агроном | 22 826 |
| | Зоотехник | |
| | Ветеринария табибы | |
| Икенче | II категорияле агроном | 22 881 |
| | II категорияле зоотехник | |
| | II категорияле ветеринария табибы | |
| Өченче | I категорияле агроном | 22 936 |
| | I категорияле зоотехник | |
| | I категорияле ветеринария табибы | |
| Дүртенче | Әйдәүче агроном | 22 991 |
| | Әйдәүче зоотехник | |
| | Әйдәүче ветеринария табибы | |
| «Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифасы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Баш агроном | 24 223» |

1.1.2. VIII бүлекнең 28 таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«28 таблица

**Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләренең башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр һәм төп окладлары күләме**

| Җитәкче хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләм күрсәткече зурлыгы (дәүләт биреме нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә белем алучылар саны), кеше* | Төп оклад, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 0 - 200 | 30 000 | 4 000 |
| 2 | 201 - 400 | 32 000 | 5 000 |
| 3 | 401 - 700 | 36 000 | 5 000 |
| 4 | 701 - 1 200 | 37 000 | 6 000 |
| 5 | 1201 – 1800 | 40 000 | 7 000 |
| 6 | 1801 һәм аннан күбрәк | 42 000 | 8 000 |

*Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешма (спорт-җайлаштыру мәктәбе) укучыларының контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына»;

1.2. 2 номерлы кушымтада II бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

**«II. Казан шәһәрендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалардагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү**

2.1. Казан шәһәрендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалардагы эшчеләрнең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 21 200 |
| Икенче | 21 398 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» | |

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 21 539 |
| Икенче | 21 713 |
| Өченче | 21 891 |
| Дүртенче | 22 422 |

2.2. Казан шәһәрендә спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалардагы җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Бер айга төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 21 200 |
| Икенче | 21 398 |
| «Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 21 539 |
| Икенче | 21 713 |
| Өченче | 21 891 |
| Дүртенче | 22 118 |
| Бишенче | 22 304 |
| «Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 22 494 |
| Икенче | 22 687 |
| Өченче | 22 884 |
| Дүртенче | 23 085 |
| Бишенче | 23 311 |
| «Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче | 24 223 |
| Икенче | 24 423 |
| Өченче | 24 623 |

2.3. Хезмәткәрнең вазифасы һәм һөнәре җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының, эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре квалификация дәрәҗәсенә туры килүе федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

2.4. Икенче эш урыны буенча эшләүче, шулай ук тулы булмаган эш вакыты

шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яки башкарылган эш күләменнән чыгып гамәлгә ашырыла. Төп вазифа, шулай ук берьюлы башкару тәртибендә биләгән вазифа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазифа буенча аерым башкарыла».

2. Әлеге карарның йогынтысы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**